Республика Татарстан
Сармановский муниципальный район
Совет Азалаковского сельского поселения
423371 с. Азалаково, ул Зеленая, дом 4
Телефон ( 85559) 4 – 80 – 36

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге Советы
423371 Азалак авылы, Яшеллек урамы, 4 йорт.
Телефон ( 85559) 4 – 80 – 36

ОГРН 1021601313381, ОКПО 93068255, ОКАТО 92253804000,
ИНН/ КПП 1636001386/163601001,ОКТМО 92653404

---

РЕШЕНИЕ КАРАР
20.09.2019 г. № 14

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруының гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октяберендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п.,Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Азалак авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«I группа инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, көндезге бүлек студентлары, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән тыш, Азалак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, 2020 елда 200 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкаруга тоту белән килешәсезме:

-Азалак, Шыгай, Юлтимер авылларында урам утлары лампалары сатып алу һәм урнаштыру;
-Азалак, Шыгай, Юлтимер авылларында (Сабантуй, 9 Май,Яңа ел) бәйрәме һәм мәдәни чаралар үткәрү өчен бүләкләр алу;
-Азалак, Шыгай, Юлтимер мәдәният йортлары өчен ясалма чыршы, Кыш Бабай һәм Кар кызы костюмнары сатып алу;
-Азалак, Юлтимер авылларында төзелеш материаллары сатып алу һәм зиратларында койма һәм будка урнаштыру буенча эш өчен түләү;
-Юлтимер, Шыгай авыллары зиратлары өчен генератор, үлән чапкыч сатып алу;
-Юлтимер авылында Яңа, Яшьләр, Үзәк, Тау, Азалак авылында Елга урамнары юлларына ремонт үткәрү һәм вак таш катламы җәю (ташу һәм вак таш җәю);
- Азалак, Шыгай, Юлтимер авылларында кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
- төзекләндерү эшләре буенча эшчеләрнең хезмәтләре өчен түләү (үлән чабу өчен);
- ГАЗ-САЗ-3512 автомашинасы һәм үлән чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу;

ӘЙЕ ЮК?»

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Азалак авыл җирлеге башлыгы: Габдулгазизов И.Г.